Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Советы карары

2019 елның 21 нче феврале № 190

Кама Тамагы муниципаль районының
2018 елда социаль-икътисадый үсеш йомгаклары
һәм 2019 елга бурычлары турында

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы Вазыйхов Наил Альберт улының Кама Тамагы муниципаль районының 2018 елда социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2019 елга бурычлары турында докладын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, муниципаль районның җирле үзидарә органнары эшчәнлеге аларның компетенцияләре һәм вәкаләтләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль район Уставы нигезендә гамәлгә ашырылды дип билгеләп үтелде .

Муниципаль органнар, гражданнар мәнфәгатьләрен кайгыртып, үз компетенциясе чикләрендә муниципаль районны үстерү планнарын һәм программаларын кабул итү һәм аларның үтәлешен контрольдә тоту, районның социаль-икътисади бурычларын тормышка ашыру, норматив хокукый базаны камилләштерү, муниципаль бюджет үтәлеше, торак пунктларда җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишүгә халыкны җәлеп итү буенча эзлекле эш алып бардылар.

Муниципаль район Советы һәм Башкарма комитетының эшчәнлеге, федераль һәм республика хезмәтләренең структур бүлекчәләре белән хезмәттәшлектә, 2018 елда районның социаль-икътисадый, инфраструктура үсеше мәсьәләләрен хәл итүгә, социаль өлкә объектларының эшчәнлеген яхшыртуга, торак белән тәэмин итүгә, халыкның реаль керемнәрен арттыруга, туристлык юнәлешен үстерүгә юнәлдерелгән иде.

Нәтиҗәдә, 2018 елда район икътисадының күп кенә тармакларында билгеләнгән темпларны ныгыта алдык.

Муниципаль район Уставының 23 һәм 38 статьялары нигезләмәләреннән чыгып, Совет һәм муниципаль район Башлыгы эшләре турында, шәһәр һәм авыл җирлекләрендәге йомгаклау җыелышларында әйтелгән тәкъдимнәрне исәпкә алып муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгының 2018 ел буенча докладын игътибарга алырга (кушымта итеп бирелә).

2. Муниципаль район башкарма комитетына Советның әлеге утырышында, җирлекләрдә яшәүче халык белән очрашуларда әйтелгән тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне анализларга, авыл хуҗалыгы үсешенең, кече һәм урта эшмәкәрлеккә

ярдәм итү мәсьәләләренә аерым игътибар бирергә, әлеге карарны үтәү буенча чаралар планын эшләргә, муниципаль район Советы депутатларын карауга кертергә һәм планлаштырылган чаралар үтәлешен оештырырга.

3.Муниципаль район Советының даими комиссияләренә үз утырышларында әлеге карарның 2 пункты буенча билгеләнгән чаралар планын үтәү барышын даими рәвештә карап тору зарур.

4. Муниципаль район Советы аппаратына муниципаль район башлыгының 2018 ел буенча докладын Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга, " Волжские зори "һәм"Идел таңнары" газеталарында бастыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район башлыгы урынбасары, муниципаль район Советы Рәисе урынбасары Г. А. Габидуллинга йөкләргә.

Кама Тамагы
муниципаль районы
Башлыгы, Кама Тамагы
муниципаль районы Советы Рәисе Н.А. Вазыйхов